РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ГЛАВА САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

31. 05. 2018

№ 90-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башлыгының 10.12.2015 178-п номерлы карары белән расланган гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының вазыйфаи затлары тарафыннан шәхси кабул итү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында” 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон), “Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау турында” 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законына ярашлы рәвештә һәм югарыда күрсәтелгән законнарга үзгәрешләр керү сәбәпле

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башлыгының “Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының вазыйфаи затлары тарафыннан шәхси кабул итү Тәртибен раслау турында” 10.12.2015 178-п номерлы карары белән расланган гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының вазыйфаи затлары тарафыннан шәхси кабул итү Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. түбәндәге эчтәлектәге 1.5. пунктын өстәргә:

“1.5. Гражданнарның кергән мөрәҗәгатьләренә анализ җирле үзидарә органының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырыла.”;

1.2. 5 пунктны төшереп калдырырга;

1.3. 7.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“7.2. Граждан үзенең язма, электрон мөрәҗәгатендә мәҗбүри рәвештә мөрәҗәгать җибәрелә торган җирле үзидарә органының исемен я тиешле вазыйфаи затның фамилиясен, исемен, атасының исемен, я тиешле затның

вазыйфасын, шулай ук үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы – булган очракта), җавап, мөрәҗәгатьне башка адреска юллау турында белдерү хаты җибәрелергә тиешле почта адресы яисә электрон адресын күрсәтә, тәкъдимнең, гариза яисә шикаятьнең асылын бәян итә. Мөрәҗәгать язмача булганда, шәхси имзасын һәм датаны куя.”;

1.4. 7.3. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“7.3. Җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка электрон документ формасында кергән мөрәҗәгать “Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында” Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә карала. Граждан мөрәҗәгатьтә мәҗбүри рәвештә үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы – булган очракта), җавап, мөрәҗәгатьне башка адреска юллау турында белдерү хаты җибәрелергә тиешле электрон почта адресын күрсәтә. Граждан кирәкле документлар һәм материалларны мондый мөрәҗәгатькә электрон формада теркәргә хокуклы.”;

1.5. 7.6. пунктта “почта” сүзеннән соң “яисә электрон” сүзләрен өстәргә;

1.6. 7.7. пунктта “почта адресы” сүзләрен “җавап җибәрелергә тиешле адрес” сүзләренә алмаштырырга;

1.7. түбәндәге эчтәлектәге 7.9. - 7.12. пунктларын өстәргә:

“7.9. Җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка электрон документ формасында кергән мөрәҗәгатькә җавап мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән электрон почта адресына электрон документ формасында һәм җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка язмача кергән мөрәҗәгатькә – почта адресы буенча язма рәвештә җавап бирелә. Моннан тыш, җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка кергән билгесез даирә затлары мәнфәгатьләренә кагыла торган тәкъдимнән, гаризадан яисә шикаятьтән гыйбарәт мөрәҗәгатькә, аерым алганда, билгесез даирә затларына карата чыгарылган суд карарына шикаять белдерелгән мөрәҗәгатькә җавап, шул исәптән суд карарына шикаять белдерү тәртибе аңлатылган җавап, “Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында” Федераль законның 6 маддәсе 2 өлеше таләпләрен үтәп, җирле үзидарә органының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылырга мөмкин.

7.10. Язмача мөрәҗәгать тексты тәкъдимнең, гаризаның яисә шикаятьнең асылын ачыкларга мөмкинлек бирмәгән очракта, мөрәҗәгатькә җавап бирелми һәм ул карау өчен тиешле компетенциясе булган органга яисә вазыйфаи затка җибәрелми, бу хакта мөрәҗәгатьне җибәргән гражданга мөрәҗәгатьне теркәгән көннән алып җиде көн эчендә хәбәр ителә.

7.11. Гражданның язмача мөрәҗәгатендә элегрәк җибәрелгән мөрәҗәгатьләренә бәйле рәвештә сорауның асылы буенча берничә тапкыр язмача җавап бирелгән мәсьәлә күтәрелгән һәм мөрәҗәгатьтә яңа дәлилләр һәм шартлар китерелмәгән очтакта, җирле үзидарә органы җитәкчесе, вазыйфаи зат яки моңа вәкаләтле зат, күрсәтелгән мөрәҗәгать һәм элегрәк җибәрелгән мөрәҗәгатьләр бер үк җирле үзидарә органына яисә бер үк вазыйфаи затка юлланган булса, чираттагы мөрәҗәгатьнең нигезсез булуы һәм әлеге мәсьәлә буенча граждан белән язышуны туктату турында карар кабул итәргә хокуклы. Әлеге карар турында мөрәҗәгать җибәргән гражданга хәбәр ителә.

7.12. Җирле үзидарә органына яки вазыйфаи затка җавабы “Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында” Федераль законның 10 маддәсе 6 өлешенә ярашлы рәвештә җирле үзидарә органының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылган мәсьәлә буенча язмача мөрәҗәгать кергән очракта, аны теркәгән көннән алып җиде көн эчендә әлеге мөрәҗәгатьне җибәргән гражданга мөрәҗәгатьтә күтәрелгән мәсьәләгә “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җавап урнаштырылган рәсми сайтның электрон адресы хәбәр ителә, бу чакта суд карарына шикаять белдерелгән мөрәҗәгать кире кайтарылмый.

1.8. 10.3. пунктка түбәндәге эчтәлектәге икенче абзац өстәргә:

“Миграция өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын бозуның булырга мөмкин фактлары турында мәгълүмат булган язмача мөрәҗәгать аны теркәгән көннән алып биш көн эчендә, аны җибәргән гражданга мөрәҗәгатьне башка адреска юллау турында хәбәр итеп, федераль башкарма хакимиятнең миграция өлкәсендә хокук куллану функцияләрен, тикшереп тору, күзәтчелек итү һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтү функцияләрен гамәлгә ашыручы органының территориаль органына һәм Татарстан Республикасы Президентына җибәрелә, моңа әлеге Тәртипнең 7.7 пунктында күрсәтелгән очрак керми.;

1.9. түбәндәге эчтәлектәге 10.9. пунктын өстәргә:

“10.9. Суд карарына шикаять белдерелгән мөрәҗәгать аны теркәгән көннән алып җиде көн эчендә, шушы суд карарына шикаять бирү тәртибен аңлатып, мөрәҗәгатьне җибәргән гражданга кире кайтарыла.”;

1.10. 14.4. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“14.4. Кабул итү урыны, кабул итү өчен билгеләнгән көннәр һәм сәгатьләр, гражданнарны кабул итүгә әзерлек өчен җаваплы вазыйфаи затларның элемтә телефоннары турындагы мәгълүмат гражданнар игътибарына “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәре һәм (яисә) массакүләм мәгълүмат чаралары аша җиткерелә. Күрсәтелгән мәгълүмат шулай ук органнар урнашкан биналарда һәркем керә алырлык урыннарда урнаштырыла.”;

1.11. 14.7. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“14.7. Шәхси кабул итү вакытында телдән бәян ителгән мөрәҗәгатьтәге фактларның һәм хәлләрнең булуы бәхәссез булса һәм аларны өстәмә тикшерү таләп ителмәсә, җавап, гражданның ризалыгы белән, кабул иткән зат тарафыннан телдән бирелергә мөмкин, бу хакта шәхси кабул итү карточкасына язып куела, ул мөрәҗәгать итүченең шәхси имзасы белән раслана. Граждан телдән бирелгән җавапка риза булмаса яисә мондый ризалык турында язманы имзасы белән раслаудан баш тартса, мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрнең асылы буенча язмача җавап бирелә.”;

1.12. 14.9. пунктының б) пунктчасына “Советлар Союзы Геройлары,” сүзләреннән соң “Дан орденының тулы кавалерлары,” сүзләрен өстәргә;

1.13. 17 пунктның б) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“б) мөрәҗәгатьтә күтәрелгән мәсьәләләрнең асылы буенча, “Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында” Федераль законның 11 маддәсендә күрсәтелгән очраклардан тыш, ә “Россия

Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында” Федераль законның 11 маддәсе 5.1. өлеше белән каралган очракта, язмача җавап бирү турында үтенеч белән мөрәҗәгать итү нигезендә, язмача җавап, язмача мөрәҗәгатьне бу мәсьәләне карау компетенциясенә кергән органга яки вазыйфаи затка юллау турында белдерү хаты алырга.”;

1.14. 21.3. пунктта “электрон” сүзен төшереп калдырырга;

1.15. 21.4. пунктта “электрон карточкадагы” сүзләрен “мөрәҗәгать карточкасындагы” сүзләренә алмаштырырга;

1.16. 22.2. пунктта “яшәү урыны адресы” сүзләрен “почта адресы яисә электрон почта адресы” сүзләренә алмаштырырга;

1.17. 22.3. пунктка “, электрон почта адресларына” сүзләрен өстәргә;

2. Әлеге карарны “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында һәм http://saby.tatarstan.ru адресы буенча Саба муниципаль районы рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р.Н. Минниханов